Мусульманская религиозная организация профессиональная образовательная организация «Казанское медресе «Мухаммадия»
Централизованной религиозной организации - Духовного управления мусульман Республики Татарстан

**Рассмотрено**
Педагогический совет(Шура)
протокол №4. от 10.09..2020

**Согласовано**
Заместитель директора
по учебной работе
Габдуллин З.Г.

**Утверждаю**
Директор
Самигуллин К.И.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
## (базовая подготовка)

## по дисциплине «Татарская литература (родная литература)»

(направление/специальность - «Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций мусульманского вероисповедания»

Составитель: Ибрагимова Л.

КАЗАНЬ 2020

**1. Наименование направления и профиля подготовки**

Направление/специальность – «Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций мусульманского вероисповедания».

Профиль подготовки – «Исламские науки и воспитание, арабский язык».

**2. Код и наименование дисциплины**

ОГС.Р.02. Татарская литература (родная литература).

**3. Цели и задачи освоения дисциплины**

**Целями** освоения дисциплины «Татарская литература (родная литература)» (далее «Татарская литература») являются сформировать у обучающихся целостное представление об истории татарской литературы; познакомить со спецификой функционирования литературных направлений и течений в татарской литературе; показать закономерности историко-литературного процесса и сформировать представление о роли татарской литературы в системе мировой культуры; сформировать представление о диалоге татарской литературы с тюркскими и европейскими литературами; научить применять полученные знания для решения задач профессиональной деятельности.

**Задачи:**

-изучать этапы развития и закономерности формирования татарской литературы;

-способствовать усвоению обучающимися основных вопросов татарской литературы;

-показать роль литературы в жизни общества;

-развивать логическое мышление обучающихся.

**4. Место дисциплины в структуре ОПОП**

Дисциплина «Татарская литература» относится к дисциплинам национально-регионального компонента общегуманитарных и социальных дисциплин (ОГС.Р.02).

Для освоения дисциплины «Татарская литература» обучающиеся используют знания, умения, навыки, сформированные в ходе изучения дисциплин «Татарский язык», «Татарская литература» в общеобразовательной школе и дисциплин «Татарский язык», «История Татарстана и татарского народа» в медресе.

Изучение дисциплины «Татарская литература» является необходимой основой для последующего изучения дисциплины «Старотатарская письменность», прохождения практики.

**5. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины**

***Национально-региональные компетенции*** (код – НРК) обеспечивают способность выпускников осуществлять профессиональную деятельность, направленную на сохранение и развитие национальной культуры в мусульманском сообществе народов Российской Федерации, исповедующих ислам. Национально-региональные компетенции включают в себя:

- осознание самоценности народно-национальной культуры и необходимости ее сохранения и развития;
- знание литературных традиций народа;

***Специальные педагогические компетенции*** (код – СПК) обеспечивают способность выпускника осуществлять образовательную деятельность по конкретным дисциплинам образовательных программ начального религиозного и среднего профессионального религиозного образования с использованием современных и традиционных для религиозного мусульманского образования методов обучения и воспитания.

.

В результате освоения дисциплины обучающийся должен:

***Знать:***

-биографию и произведения татарских писателей;

-особенности татарской литературы;

-литературные, культурные и религиозные традиции татарского народа;

-связь литературы с другими науками, религией.

***Уметь*:**

-владеть различными методами изучения литературы;

-анализировать литературные произведения;

-реализовывать на практике полученные знания и навыки;

-выстраивать толерантные отношения с людьми, имеющими различные взгляды относительно религии и веры.

***Владеть навыками:***

-работы с учебной, научной и справочной литературой;

-работы с современными информационными технологиями для обеспечения качества учебно-воспитательного процесса.

## 6. Структура и содержание дисциплины

### 6.1. Общая трудоемкость дисциплины составляет 102 часа

| Виды учебной работы | Всего часов | Семестр | |
|---|---|---|---|
| | | 3 | 4 |
| Общая трудоемкость дисциплины | 102 | 50 | 52 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аудиторные занятия | 68 | 34 | 34 |
| Лекции | 32 | 16 | 16 |
| Практические занятия (ПрЗ) | 36 | 18 | 18 |
| Семинары (С) | - | - | - |
| Лабораторные работы (ЛР) | - | - | - |
| Курсовая работа (КР) | - | - | - |
| Самостоятельная работа студентов (СРС) | 34 | 16 | 18 |
| Вид итогового контроля (контрольная работа, зачет, экзамен) | | контрольная работа | зачет |

## 6.2. Содержание дисциплины

| № п/п | Наименование и содержание тем занятий | Лекции (часы) | Практические занятия (часы) | Семинары (часы) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | **Кереш**<br>Курсның өйрәнү объекты, максат-бурычлары. Әдәби әсәрләрдә рухи кыйммәтләрнең чагылышы. Әдәбият фәненең тәрбияви әһәмияте.<br>Татар әдәбиятының чорларга бүленеше мәсьәләсе:<br>-Борынгы татар әдәбияты.<br>-XIX гасыр әдәбияты.<br>-XX гасыр башы әдәбияты.<br>-XX гасыр – XXI гасыр башы әдәбияты.<br>Әдәбиятта татар дөньясының милли образы, татар милли характеры.<br>Мәдәни, рухи мирас. Аны өйрәнүнең әһәмияте. | 2 | 2 | |
| 2 | **Халык авыз иҗаты**<br>Халык җырлары, әкиятләре, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр. Бәетләр, мөнәҗәтләр. Бишек җырлары, балалар фольклоры. | 2 | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Мифлар, легендалар, мәзәкләр. Г. Тукай – халык авыз иҗаты турында. | | | |
| 3 | **Борынгы татар әдәбияты**<br>Борынгы татар әдәбиятын чорларга бүлеп өйрәнү:<br>-Иң борынгы гомумтөрки әдәбият;<br>-Болгар дәүләте чоры татар әдәбияты;<br>-Алтын Урда чоры татар әдәбияты;<br>-Казан ханлыгы чоры татар әдәбияты;<br>-XVII-XVIII гасырлар татар әдәбияты. | 2 | 2 | |
| 4 | **Иң борынгы гомумтөрки әдәбият (V-XII гасырлар)**<br>Борынгы төркиләр. Аларда язу барлыкка килү. Рун язулы истәлекләр. Орхон-Енисей язмалары. Мәхмүд Кашгарыйның “Диване лөгатет-төрк” сүзлеге (1072-1074). Йосыф Баласагунлының “Котадгу белек” поэмасы (1069-1070). Хуҗа Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани, Әхмәд Йүгнәки иҗатлары. | 2 | 2 | |
| 5 | **Болгар дәүләте чоры татар әдәбияты (X-1236)**<br>Болгар дәүләте чорына тарихи анализ. “Бәдәвам китабы”. Кол Гали (1198-1236) һәм аның “Кыйссаи Йосыф” поэмасы (1233). Коръән һәм татар әдәбияты. | 2 | 2 | |
| 6 | **Алтын Урда чоры татар әдәбияты (1236-1445)**<br>Чорга тарихи күзәтү. Бу чор әдәбиятына хас үзенчәлекләр. Алтын Урда шагыйрьләре Котб (“Хөсрәү вә Ширин” поэмасы, 1342), Харәзми (“Мәхәббәтнамә” поэмасы, 1354), Мәхмүд бине | 2 | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Гали (“Нәһҗ эл-фәрадис” әсәре, 1358), Хисам Кятиб (“Җөмҗемә солтан” дастаны, 1370), Сәйф Сараи (“Гөлстан бит-төрки”, 1391; “Сөһәйл вә Гөлдерсен”, 1394) иҗатлары. | | | |
| 7 | **Казан ханлыгы чоры татар әдәбияты (1445-1552)** Казан ханлыгы оешу. Чорга гомуми күзәтү. Казан шагыйре Мөхәммәдьяр әсәрләре (“Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары һ.б.). Кол Шәриф иҗаты. | 2 | 2 | |
| 8 | **XVII-XVIII гасырлар татар әдәбияты (1552-1800)** XVII гасыр әдәбиятына күзәтү. Татар әдәбиятында суфичылык мотивлары. Мәүлә Колый “хикмәт”ләре. XVIII гасырда яңа жанр төрләре. Габдрәхим Утыз Имәнинең иҗтимагый һәм әдәби эшчәнлеге. | 2 | 2 | |
| 9 | **XIX гасыр әдәбияты (1800-1905)** XIX гасырда булган иҗтимагый-тарихи вакыйгалар һәм әдәби хәрәкәт. Казан университеты ачылу (1804), Ватан сугышы (1812), Декабристлар восстаниесе (1825), Кырым сугышы (1853-1956), крепостной тәртипләрне бетерү (1861) һ.б. Университетта эшләгән татар галимнәре И. Хәлфин, М. Мәхмүдов, Г. Ваһапов хезмәтләре. Ә. Каргалый, Г. Кандалый һәм аларның иҗаты. Татар мәгърифәтчелек хәрәкәте формалашу. Җәдитчелек. Күренекле мәгърифәтче К. Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты. Мәгърифәтчелек реализмы. М. Акмулла, М. Акъегет әсәрләре белән танышу. | 2 | 4 | |
| 10 | **XX гасыр башы әдәбияты (1905-** | 2 | 4 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **1917**)<br>XX гасыр башына караган иҗтимагый-тарихи вакыйгаларга анализ. Рус-япон сугышы (1904-1905), Беренче рус революциясе (1905-1907), Столыпин реформалары (1907-1911) һ.б.<br>XX гасыр башында әдәби юнәлешләр, иҗат ысуллары. Реализм һәм романтизм.<br>Татар прозасы. Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камаллар иҗаты белән танышу.<br>Ф. Әмирханның заман тормышының төрле якларын яктырткан әсәрләре (“Хәят” (1911) повесте, “Урталыкта” (1912) романы һ.б.). “Хәят” әсәренең бүгенге көн проблемалары белән аваздашлыгы.<br>Поэзия. Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Ш. Бабич, Н. Думавилар иҗатына күзәтү ясау. Г. Тукай, Дәрдемәнд иҗатларында халык-милләт язмышы.<br>Драматургия. Г. Камал, Г. Коләхмәтов, М. Фәйзи эшчәнлеге. | | | |
| 11 | **XX гасыр – XXI гасыр башы әдәбияты (1917-2015)**<br>Чорга күзәтү. Февраль һәм Октябрь революцияләре (1917), Гражданнар сугышы (1917-1922), “күмәкләштерү хәрәкәте”, дингә каршы аяусыз көрәш, Сталинның “шәхес культы” (1930 нчы еллар), Бөек Ватан сугышы (1941-1945) һәм башка вакыйгаларга анализ. Әлеге вакыйгаларның әдәбиятта чагылышы.<br>XX гасыр – XXI гасыр башы әдәбиятының бүленеше:<br>-Совет чоры татар әдәбияты;<br>-XX гасыр ахыры татар әдәбияты; | 2 | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | -XXI гасыр башы әдәбияты. | | | |
| 12 | **Совет чоры татар әдәбияты (1917-1985)**<br>1917-1930 нчы еллар әдәбияты.<br>Октябрь революциясе, Гражданнар сугышы һәм әдәбият. Әдәбиятта сыйнфыйлык. К. Тинчурин, Ш. Усманов, Г. Ибраһимов, Ф. Бурнашлар иҗаты белән танышу.<br>1930-1941 нче еллар әдәбияты.<br>Т. Гыйззәт иҗаты. Сәхнә әсәрләре язучы буларак, иҗатының үсеш этаплары, пьесаларда ул яктырткан темалар. К. Нәҗми иҗаты. Сыйнфый көрәшне тасвирлавы иҗатының төп темасы булып әверелү.<br>Сугыш чоры әдәбияты (1941-1945).<br>Бөек Ватан сугышы чорына күзәтү. Сугыш елларында әдәбиятның роле. Әдәбиятта сугыш темасы. М. Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. Шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы шигырьләре. Ф. Кәрим иҗаты.<br>Тыныч тормышка күчү чоры әдәбияты.<br>Х. Туфан, С. Хәким шигърияте. Проза һәм драмматургия өлкәсенә хас үзенчәлекләр. Сугыш китергән хәсрәт темасын һәм сугышта җиңеп чыгу шатлыгын гәүдәләндерү. Тыныч тормыш һәм хезмәт темасы. | 4 | 4 | |
| 13 | **XX гасыр ахыры татар әдәбияты (1985-2000)**<br>Чорга хас тарихи-иҗтимагый вакыйгалар. Үзгәртеп кору сәясәте. Советлар берлегенең таркалуы. 1990 нчы еллардагы вазгыять. | 4 | 4 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Эшчеләр тормышын, татар авылын, халкыбыз тарихын сурәтләгән әсәрләр. Ә. Еники, Г. Бәширов, А. Гыйләҗев, М. Хәбибуллин, Н. Фәттах, М. Мәһдиев иҗатларын анализлау. | | | |
| 14 | **XXI гасыр башы әдәбияты (2000-2015)**<br>XXI гасыр башы әдәбиятына күзәтү ясау. Р. Батулла, Ф. Садриев, В. Имамов һәм Ф. Сафиннар иҗаты. Алар тарафыннан күтәрелгән темалар.<br>Татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән бәйләнеше. Әдәбиятта татар булмаган милләт вәкилләренең сурәтләнеше. Татарстанның төп байлыгы – халыклар дуслыгы. | 2 | 2 | |
| | **Всего:** | 32 | 36 | |

## 7. Учебно-методическое и информационное обеспечение дисциплины

### 7.1 Рекомендуемая литература

**Основная литература**

1. Сибгатуллина, А. Т. Татар дини-югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма : учебное пособие / А. Т. Сибгатуллина. - Казань : Казанский ун-т, 2013. - 184 с. - ISBN 978-5-00019-048-7. - Текст : электронный. - URL: https://znanium.com/catalog/product/1216363

2. Миннегулов, Х. Ю. Восточная классика и татарская литература : учебное пособие / Х. Ю. Миннегулов. - Казань : Яз, 2014. - 292 с. - ISBN 978-5-904449-93-3. - Текст : электронный. - URL: https://znanium.com/catalog/product/1216075

**Дополнительная литература**

1. Зайнуллин, Г. Г. Мөнәҗәтләр, бәетләр һәм тарихи җырлар : учебное пособие / Г. Г. Зайнуллин. - Казань : Казан. ун-т, 2014. - 61 с. - ISBN 978-5-00019-271-9. - Текст : электронный. - URL: https://znanium.com/catalog/product/1216409.

### 7.2.Программное обеспечение и Интернет-ресурсы

Программы:

Microsoft Word

ABBYY Fine Reader

Интернет-ресурсы:
-Электронная библиотека: http://koob.ru
-http://www.tatknigafund.ru
-kazan-utlari.kaz24.ru
-idel-journal.ru
-Аудио- и видео- пособия, учебное телевидение.
-Яндекс. Словари > гуманитарные науки.

### 7.3. Материально-техническое обеспечение дисциплины

Технические средства:
1. Видеопроектор.

/

## 8. Методические рекомендации (материалы) для преподавателя

«Татарская литература» в сочетании с другими практическими и теоретическими дисциплинами должен обеспечить всестороннюю подготовку будущего преподавателя основ ислама, способного квалифицированно осуществлять свою профессиональную деятельность.

Изучение дисциплины «Татарская литература» осуществляется на аудиторных занятиях под руководством преподавателя и в ходе самостоятельной работы обучающихся. Существенным дополнением служат учебно-методические, иллюстративные материалы.

Методы и приемы:
-историко-сопоставительный;
-структурный;
-статистический анализ;
-наблюдения;
-описательный.

### Методика БРС
### Порядок организации процедуры

Успешность изучения дисциплины «Татарская литература» в 2-х семестрах, имеющей форму контроля *контрольная работа/зачет*, оценивается исходя из 100 максимально возможных баллов за семестр.

**На текущий и рубежный контроль по дисциплине отводится 100 баллов.**

Рекомендуемый объем баллов на текущий контроль:

- *выполнение графика аудиторной работы по дисциплине и контроль посещаемости* – не более 30 баллов;

- *выполнение графика самостоятельной работы по дисциплине* – не более 20 баллов.

Рекомендуемый объем баллов на рубежный контроль:

- *семестровые контрольные мероприятия* – не более 50 баллов.

Обучающийся получает оценку «зачтено», если в ходе текущего и рубежного контролей он набрал по дисциплине не менее 50 балла.

## 11. Методические указания для обучающихся

### Методические рекомендация для написания реферата по татарской литературе. (Образец)

### Татар әдәбиятыннан реферат язу өчен методик күрсәтмәләр. (Үрнәк)

#### 1) Реферат өчен тема сайлау

Тема сайлау бик җаваплы мәсьәлә. Шунлыктан, студент теманы фәнни җитәкче белән берлектә сайлый. Укытучы студентның белем дәрәҗәсенә, эшли белү күнекмәләренә игътибар итә.

*Әдәбияттан үрнәк темалар:*

1)“Г. Тукай һәм халык авыз иҗаты”;

2)“М. Җәлил – азатлык җырчысы”;

3)“М. Мәһдиев иҗатында авыл темасы” һ.б.

Темалар артык киң яки артык катлаулы булырга тиеш түгел. Мәсәлән, “Татар халык авыз иҗаты”, “Татар поэзиясе”, “Татар прозасы” һәм башка шундый типтагы темалар бирергә ярамый.

#### 2) Рефератны язу барышында материаллар туплау

Материал җыю, аларны билгеле бер тәртипкә салу тикшеренүчедән билгеле бер эш күнекмәләрен сорый.

Материалны кайдан туплап була?

Матералны әдәби әсәрләрдән, фәнни-теоретик әдәбияттан, газета-журналлардан, музей һәм архивлардан тупларга мөмкин.

#### 3) Хезмәтне техник яктан дөрес оештыру

Татар әдәбиятына караган рефератлар түбәндәге структурага ия:

- Эчтәлек.
- Кереш.
- Аерым бүлекләрдән гыйбарәт төп өлеш.
- Йомгак.
- Файдаланылган әдәбият исемлеге.

*Кереш өлеш.* Кереш өлештә хезмәтнең актуальлеге исбатлана, тикшеренүләрнең объекты һәм предметы күрсәтелә, максат-бурычлары билгеләнә. Автор тарафыннан кулланылган метод-алымнар белән методологик база да күрсәтелергә тиеш. Алга таба эшнең фәнни яңалыгы һәм гамәли әһәмияте дәлилләнә. Гадәттә, кереш ахырында эшнең структурасы бирелә.

*Төп өлеш.* Төп өлеш бүлекләрдән тора, ә бүлекләр исә үз чиратында аерым бүлекчәләргә бүленә. Һәрбер бүлек төп максатка ирешү юлында

конкрет бер мәсьәләне чишүгә корыла һәм кыскача нәтиҗәләр ясау белән тәгалләнә. Бүлекләр бер-берсеннән аерымланган хәлдә яши алмыйлар. Аларда күтәрелгән проблемалар арасындагы фәнни эзлеклелекне саклау шарт.

Фәнни эшнең беренче бүлеге, гадәттә, төбәк яки регион тарихын өйрәнүгә багышланса, икенче бүлек җирле ономастиканы тикшерүгә корыла.

*Йомгак.* Фәнни тикшеренү эшләренә йомгак ясау аеруча зур осталык сорый. Ул төпле һәм ныклы уйланылган булырга тиеш. Йомгак, кереш өлеш кебек үк, күп сүзле була алмый, чөнки анда конкрет фәнни һәм гамәли нәтиҗәләр ясала.

*Файдаланылган әдәбият исемлеге.* Файдаланылган әдәбият исемлеге – библиографик аппарат элементы. Аңарда хезмәттә кулланылган чыганакларның һәм теоретик хезмәтләрнең библиографик тасвирламасы бирелә. Ул йомгаклау өлешеннән соң урнаштырыла. Барлык хезмәтләрнең дә тулы битләре саны күрсәтелә.

Фәнни хезмәтләрдә библиографик исемлекне төзүнең түбәндәге юлларыннан файдаланалар: авторларның фамилияләре яки хезмәт исемнәре элифба һәм хронологик тәртип буенча, тематика буенча, басма төрләре буенча, эчтәлек характеры буенча бирелә; катнаш төзелешкә ия исемлекләр дә була.

*Авторларның фамилияләре әлифба тәртибендә бирелгән очракка мисал:*

1. Гыйлаҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2007.

2. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006.

*Кушымта.* Хезмәтләрдә кушымтадан файдалану аларның гамәли әһәмиятен тагын да арттыра төшә.

Кушымта төрле характерда булырга мөмкин. Мәсәлән, документларның күчермәләре, отчёт материалларыннан өземтәләр, һәртөрле планнар һәм беркетмәләр, моңарчы бастырылмаган текстлар, сүзлекләр һ.б. Форма ягыннан алар текст, таблица, график яки карта рәвешендә була ала.

Кушымта рефератның дәвамы рәвешендә, аның ахыргы битләрендә бирелә.

Һәрбер кушымта яңа биттән башланырга тиеш. Бит өстенә “Кушымта” дип куела һәм аның исеме күрсәтелә. Берничә кушымта булганда алар гарәп саннары белән номерлана, мәсәлән: “Кушымта 1”, “Кушымта 2”.

## 4) Сылтама һәм астөшермәләрне күрсәтү тәртибе

*1)Текст эчендәге сылтамага мисал:*

Каләм әһелләре әледән-әле искәркәнчә, һәрбер әдип насыйп гомере дәвамында үзенең бердәнбер зур китабын яза [1, б. 3].

*2)Астөшермәгә мисаллар:*

Кеше, кайсы якларга гына китеп яшәргә мәҗбүр булса да, күңеле белән һәрвакыт туган якка тартыла: шул җирләрне кайтып күрү теләге белән яна, иртәме-соңмы, шушы җиргә кайтып, хатирәләрен яңарта[1].

*Шул ук хезмәттән кабат файдаланган очракта:*Әнә уңда – үзләренә атап җыр, көй иҗат ителгән яшь имәннәр, сулда –яшел шәл бөркәнгән усаклар. Түбәнрәк төшсәң, зиреклек урманы башлана[2].

### 5) Рефератта файдаланылган әдәбият исемлеген (библиографияне) күрсәтү

*1)Китаптан алынган материаллар:*

*2)Энциклопедия һәм сүзлектән алынган материаллар:*

Татарский энциклопедический словарь. – Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 1999. – 703 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, 2 т. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1979. – 726 б.

*3)Газета-журнал материаллары:*

Хәбибуллин М. Хазарлар / М. Хәбибуллин // Мәйдан. – 2005. – № 1. – Б. 115-131.

Шәфыйков Я. Актанышка кайта юлларым / Я. Шәфыйков // Шәһри Чаллы. – 2006. – 17 нче гыйнвар.

*4)Конференция материаллары:*

Галиуллин Т.Н. Тукайның әхлак дәресләре / Т.Н. Галиуллин // Сборник статей и тезисов Всероссийской научно-практической конференции “Роль ислама в стабилизации социальных процессов”. – Набережные Челны; Ак мечеть, 2014. – С. 102-105.

### 6) Рефератны бастыру

Реферат А-4 форматлы стандарт кәгазьнең бер ягында, юллар арасында 1,5 интервал калдырылып, 14ле шрифт белән компьютерда бастырыла. Битләрдә сул яктан 30 мм, уңнан 10 мм, өстән һәм астан 20 мм ара калдырыла.

Бит саны өстә, уртада күрсәтелә.

Рефератның күләме 15 биттән дә артмаска тиеш.

## 12. Контрольные материалы по внутрисеместровой, промежуточной аттестации и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы обучающихся

### Тестовые задания

---

[1] Ринат Баттал. Йөрәгемдә – авылым назы // Мәйдан. – 2015. – № 2. – Б. 22.

[2] Шунда ук. – Б. 23.

**Вариант №1**

Инструкция: выберите наиболее полный и верный ответ на каждое их утверждений и отметьте его на бланке, обведя кружком или зачеркнув. Не рекомендуется долго размышлять над каким-либо одним утверждением.

**1. Орхон-Енисей чыганакларын беренче булып укыган галим**

1) В.Томсен
2) Н.Ф.Катанов
3) В.В.Радлов
4) Н.И.Ильминский

**2. Борынгы татар әдәбияты колачлаган чор**

1) Иң борынгы чорлардан алып 1800 нче елга кадәр
2) 1800-1905 нче еллар
3) 1905-1917 нче еллар
4) 1917-2000 нче еллар

**3. “Күктән килде – җиргә китте” табышмагының җавабы**

1) Җил
2) Тузан
3) Яңгыр
4) Давыл

**4. Халык авыз иҗаты үрнәгенең төрен билгеләгез: “Хезмәт иясе – хөрмәт иясе”**

1) Табышмак
2) Мәзәк
3) Тизәйткеч
4) Мәкаль

**5. “Хөсрәү вә Ширин” поэмасының авторы**

1) Харәзми
2) Котб
3) Хисам Кятиб
4) Мәхмүд бине Гали

**6. “Хикмәт”ләр хуҗасы**

1) Г.Кандалый
2) Г.Чокрый
3) М.Колый
4) Ә.Каргалый

**7. Татар прозасына нигез салучы**

1) Г.Исхакый
2) Ф.Әмирхан
3) Г.Ибраһимов
4) Ш.Камал

**8. Г.Ибраһимов әсәре**
1) “Ике йөз елдан соң инкыйраз”
2) “Акчарлаклар”
3) “Алмачуар”
4) “Фәтхулла хәзрәт”

**9. “Моабит дәфтәре” авторы**
1) М.Җәлил
2) А.Алиш
3) Ф.Кәрим
4) Х.Мөҗәй

**10. Яр Чаллы шәһәрендә нәшер ителүче әдәби-нәфис, иҗтимагый журнал**
1) “Казан Утлары”
2) “Сөембикә”
3) “Чаян”
4) “Мәйдан”

**Вариант №2**

Инструкция: выберите наиболее полный и верный ответ на каждое их утверждений и отметьте его на бланке, обведя кружком или зачеркнув. Не рекомендуется долго размышлять над каким-либо одним утверждением.

**1. Орхон-Енисей чыганакларын икенче булып укыган рус галиме**
1) И.Н.Березин
2) Н.Ф.Катанов
3) В.В.Радлов
4) Н.А.Баскаков

**2. “Башы тауда, аягы диңгездә” табышмагының җавабы:**
1) Тамчы
2) Йолдыз
3) Елга
4) Буран

**3. Халык авыз иҗаты үрнәгенең төрен билгеләгез:**
**“Яңгыр яу, яу, яу,**
**Иләктән, чиләктән, пәрәмәчтән, коймактан,**

**Арыштан, бодайдан,**
**Без сорыйбыз Ходайдан.**
**Бир, Алла, бир Алла!**
**Биргәнеңне кире алма".**

1) Сынамыш
2) Бишек җыры
3) Әкият
4) Эндәш

**4. "Җөмҗемә солтан" дастанының авторы**

1) Сәйф Сараи
2) Хисам Кятиб
3) Харәзми
4) Мәхмүд бине Гали

**5. Герой-шагыйрь**

1) М.Җәлил
2) Х.Туфан
3) С.Хәким
4) Г.Бәширов

**6. "Галиябану" драмасының авторы**

1) М.Акъегет
2) Габдрәхим Утыз Имәни
3) Г.Тукай
4) М.Фәйзи

**7. Г.Исхакый әсәре**

1) "Сөннәтче бабай"
2) "Тирән тамырлар"
3) "Памирдан радио"
4) "Тапшырылмаган хатлар"

**8. Проза әсәре төре**

1) Шигырь
2) Роман
3) Поэма
4) Дастан

**9. Поэзия өлкәсенә караган әсәр төре**

1) Хикәя
2) Повесть
3) Роман
4) Шигырь

**10. Яр Чаллы төбәгендә яшәп иҗат итүче язучы**
1) Ф.Садриев
2) Ф.Сафин
3) М.Галиев
4) К.Кәримов

**Перечень контрольных вопросов для самостоятельной работы**
1. Борынгы төркиләрдә язу барлыкка килү.
2. Коръән һәм татар әдәбияты.
3. Коръәндә “Йосыф” сүрәсе.
4. Татарларда бишек җырлары.
5. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятының эчке бүленеше.
6. Мөхәммәт Әмин иҗаты.
7. Ш. Мәрҗанинең дини-гыйльми эшчәнлеге.
8. Казан – Россиядәге мәдәни һәм дини үзәкләрнең берсе.
9. Татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән багланышы.
10. Татар әдәбиятын өйрәнү өлкәсендә эшләгән галимнәр һәм аларның хезмәтләре.

*Әдәбият:*

1. Гыйлаҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар. – Казан: Мәгариф, 2007.
2. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006.
3. Хәзерге татар әдәбияты / Төзүчеләре: Закирова Г.Р., Гыйззәтуллина Л.Ә. – Казан: Мәгариф, 2008.

## Комплект заданий для контрольной работы

### Тема: Халык авыз иҗаты

**Вариант 1.**
1) Халык авыз иҗатының максаты.
2) Татар халык әкиятләрендә гаделлек.

**Вариант 2.**
1) Татар халык табышмакларының әһәмияте.
2) Халык авыз иҗатының әдәбиятка йогынтысы.

### Тема: Борынгы татар әдәбияты

**Вариант 1.**
1) Татар әдәбияты тарихы нинди чорларга бүленә?
2) Борынгы әдәбият әсәрләренә ислам диненең йогынтысы.

**Вариант 2.**
1) Борынгы татар әдәбияты әсәрләренә хас үзенчәлекләр.

2) Кол Галинең “Кыссаи Йосыф” поэмасында күтәрелгән гуманистик идеаллар.

### Тема: XIX гасыр әдәбияты

**Вариант 1.**

1) XIX гасырда булган иҗтимагый-тарихи вакыйгаларны шул чор әдәбияты белән бәйләп аңлатыгыз.

2) Татар мәгърифәтчелек хәрәкәте формалашуга китергән сәбәпләр.

**Вариант 2.**

1) К. Насыйри эшчәнлегенең әһәмияте.

2) Мәгърифәтчелек реализмы.

### Тема: XX гасыр башы әдәбияты

**Вариант 1.**

1) XX гасыр башында булган әдәби юнәлешләр.

2) XX гасыр башы поэзиясенә күзәтү ясагыз.

**Вариант 2.**

1) Реализм һәм романтизм.

2) XX гасыр башы прозасына хас үзенчәлекләр.

### Тема: XX гасыр – XXI гасыр башы әдәбияты

**Вариант 1.**

1) XX гасыр – XXI гасыр башы әдәбиятын чорларга бүлү мәсьәләсе.

2) “Шәхес культы”н чагылдырган әсәрләр.

**Вариант 2.**

1) Бөек Ватан сугышы һәм татар әдәбияты.

2) Татар әдәбиятында авыл темасы.

## Темы рефератов

### Тема: Халык авыз иҗаты

1. Халык авыз иҗаты һәм татар әдәбияты.
2. Аң-белемнең әһәмиятен чагылдырган табышмаклар.
3. Мәкаль-әйтемнәрдә яшь буынны тәрбияләү проблемасы.
4. Бәетләр.
5. Халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю-барлау өлкәсендә эшләгән галимнәр.

*Әдәбият:*

1. Бала бишеге – гомер ишеге. 2 нче басма. – Яр Чаллы: “Идел-йорт” нәшрияты, 2002.

2. Татар халык табышмаклары. – Яр Чаллы: “Идел-йорт” нәшрияты, 2002.

**Тема: Борынгы татар әдәбияты**

1. Кешелек тарихында әдәбиятның урыны.
2. Борынгы әдәбият әсәрләренә ислам диненең йогынтысы.
3. М. Кашгарыйның “Диване лөгатет-төрк” китабы.
4. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәренең татар халкы тормышындагы әһәмияте.
5. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә әхлак темасы.
6. Хисам Кятибның “Җөмҗемә солтан” дастанының идея-эстетик кыйммәте.
7. Сәйф Сараиның “Гөлстан бит-төрки”, “Сөһәил вә Гөлдерсен” әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар.
8. Мөхәммәдьяр иҗатында гомумкешелек кыйммәтләре.
9. Мәүлә Колый “хикмәт”ләре.
10. Габдрәхим Утыз Имәни иҗатының әһәмияте.

*Әдәбият:*

1. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006.
2. Шәрипов Ә.М. Борынгы татар әдәбиятының авыр үзләштерелә торган мәсьәләләре: студентларга методик кулланма. – Яр Чаллы, 2008.
3. XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. – Казан: Дом печати, 2006.

**Тема: XIX гасыр әдәбияты**

1. Ә. Каргалыйның тормыш юлы һәм иҗаты.
2. Г. Кандалыйның татар поэзиясенә алып килгән яңалыгы.
3. К. Насыйриның тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге.
4. М. Акъегетнең “Хисаметдин менла” повестенда мәгърифәтчелек.
5. Р. Фәхретдин – дин галиме, тарихчы, педагог, журналист.

*Әдәбият:*

Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006.

**Тема: XX гасыр башы әдәбияты**

1. Гаяз Исхакый – яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салучы прозаик, драматург
2. Г. Тукай иҗатының әһәмияте.
3. Дәрдемәнд – талантлы шагыйрь.
4. Г.Ибраһимовның әдәби һәм фәнни эшчәнлеге.
5. М.Фәйзи драматургиясенең үлемсезлеге.
6. Татар театры тарихы.

*Әдәбият:*

1. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006.

2. Гыйлаҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар. – Казан: Мәгариф, 2007.

**Тема: XX гасыр – XXI гасыр башы әдәбияты**

1. Х.Туфан иҗатында образлар.
2. С.Хәким шигъриятендә сугыш темасы.
3. Ә.Еники – хикәя һәм повестьлар остасы.
4. Г.Бәширов – татар әдәбияты аксакалы.
5. М.Мәһдиев – авылга мәдхия җырлаучы әдип.
6. Халык язмышын яктыртуда тарихи романнарның әһәмияте.

*Әдәбият:*

Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006.

**Перечень вопросов к зачету**

1. Татар әдәбияты курсының өйрәнү объекты, максат-бурычлары.
2. Әдәбиятта татар дөньясының милли образы, татар милли характеры.
3. Әдәби әсәрләрдә рухи кыйммәтләрнең чагылышы.
4. Әдәбият фәненең тәрбияви әһәмияте.
5. Татар әдәбиятының чорларга бүленеше.
6. Халык җырлары, әкиятләре, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр.
7. Бәетләр, мөнәҗәтләр.
8. Бишек җырлары, балалар фольклоры.
9. Мифлар, легендалар.
10. Рун язулы истәлекләр. Орхон-Енисей язмалары.
11. Мәхмүд Кашгарыйның “Диване лөгатет-төрк” сүзлеге.
12. Йосыф Баласагунлының “Котадгу белек” поэмасы.
13. Хуҗа Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани, Әхмәд Йүгнәки иҗатлары.
14. Әдәбият һәм дин арасындагы бәйләнешләр.
15. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасында күтәрелгән дөньяви мәсьәләләрнең дини-әхлакый фикерләр белән үрелеп баруы.
16. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” поэмасы.
17. Харәзминең “Мәхәббәтнамә” поэмасы.
18. Мәхмүд бине Галинең “Нәһҗ эл-фәрадис” әсәре.
19. Хисам Кятибнең “Җөмҗемә солтан” дастаны.
20. Сәйф Сараиның “Гөлстан бит-төрки”, “Сөһәйл вә Гөлдерсен” әсәрләре.

21. Казан шагыйре Мөхәммәдьяр әсәрләре (“Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары һ.б.).

22. Кол Шәриф иҗаты.

23. XVII гасыр әдәбияты. Мәүлә Колый “хикмәт”ләре.

24. XVIII гасырда яңа жанр төрләре. Габдрәхим Утыз Имәнинең иҗтимагый, әдәби эшчәнлеге.

25. Ә. Каргалый иҗаты.

26. Г. Кандалый поэмалары.

27. Татар мәгърифәтчелек хәрәкәте.

28. Җәдитчелек.

29. Күренекле мәгърифәтче К. Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты.

30. Мәгърифәтчелек реализмы.

31. Реализм һәм романтизм.

32. Г. Исхакый – татар прозасына нигез салучы.

33. Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты.

34. Ф. Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты. “Хәят” әсәренең бүгенге көн проблемалары белән аваздашлыгы.

35. Г. Камалның тормыш юлы һәм иҗаты.

36. С. Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗаты.

37. Дәрдемәнднең тормыш юлы һәм иҗаты.

38. Тукай, Дәрдемәнд иҗатларында халык-милләт язмышы.

39. 1917-1930 нчы еллар әдәбияты.

40. 1930-1941 нче еллар әдәбияты.

41. Бөек Ватан сугышы чоры (1941-1945) әдәбиятына гомуми күзәтү ясарга.

42. Татар әдәбиятында Ватанга тугрылык темасы.

43. М. Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты.

44. Ф. Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты.

45. Х. Туфанның тормыш юлы һәм иҗаты.

46. С. Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты.

47. Ә. Еникинең тормыш юлы һәм иҗаты.

48. А. Гыйләҗев иҗатында чынбарлыкның бирелеше.

49. М. Мәһдиев әсәрләрендә авыл темасы.

50. XXI йөз башы татар әдәбиятының торышы.

51. Яр Чаллы төбәге язучылары.

52. Татар әдәбиятының башка (төрки һәм төрки булмаган) әдәбиятлар белән бәйләнеше.

53. Әдәбиятта татар булмаган башка милләт вәкилләренең сурәтләнеше.

54. Татарстанның төп байлыгы – халыклар дуслыгы.